«КИЛЕШТЕРЕЛДЕ»
Әлмәт муниципаль районы һәм
Әлмәт шәһәре хәрби комиссары
_______________ Р.Р. Сабиров
«_8_» _______________2021ел

«РАСЛЫЙМ»
Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авылы
Башкарма комитеты җитәкчесе
_______________ С.А. Белоногов
«_8_» _______________2021 ел

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авылы Башкарма комитеты

КАРАРЫ

«_8_»_июнь_ 2021 ел №_3_

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориядә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы» нигезләмәне раслау

Россия Федерациясе Конституциясе, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу буенча нигезләмәне раслау турында» 719 номерлы, 2020 елның 06 февралендәге 103 номерлы «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» күрсәтмәсе,Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге Уставы нигезендә

Рус Акташы авылы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне (1 нче кушымта нигезендә) расларга.

2. Хезмәткәрнең беренчел хәрби исәпкә алу буенча вазыйфаи инструкцияләрен расларга (2 нче кушымта нигезендә).

3. Запаста торучы һәм чакырылырга тиешле гражданнарны, гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны алып бару бурычын Рус Акташы авылы Башкарма комитетына йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авылы җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 12 апрелендаге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне раслау турында» 1 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

5. Әлеге карарны Рус Акташы авылы, Төзүчеләр урамы, 14 нче йорт; Комсомол урамы, 12б йорты территориясендә; Акташ станциясе контора бинасында урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рус Акташы
авыл җирлеге Башлыгы С.А.Белоногов